

Козге ярмарка сентябрь башында vтте инде. Бездә алар еш була. Халык аннан арзан бәягә ашамлыклар алганга, анда халык яратып йори. 28нче октябрьдә Саранск шәһәренен һәрбер районында, Олкәннәр аена да туры китерелгән авыл хужалыгы ярминкәсе булып vтте. Ярмарка киштәләрендә нигездә кvбрәк жәй конендә vстерелгән байлыклар урын алган иде.
Сатуда 190 сум/кг - сыер ите (дунгызныкы - 165), кош ите – тавык - 85 сум/кг, кvркә - 170), сарык ите 300 сумнан килограммы, каты сортлы сыр- 290 сум/кг, мәсәлән, «Пармезан» или «Чеддер» бәярәк булса да халык яратып кvп иттереп алдылар. Ә йомырка турында әйтәсе дә юк, утыз сумнан дистәсен халык рәхәтләнеп алды, чираты да юк диярлек. Рафинировать ителгән конбагыш мае 55 сумнан литры һәм шикәр комы 29 сум килограммы. Шулай ук он, корпә, яшелчә, балык, консервлар, эчемлекләр, кондитер һәм макарон продукциясе һәм башка тор ашамлыклар сатылды. «Татлытамаклар» очен куертылган сот, бал да сатып алырга була иде. Эшкәртv предприятияләре продукциясеннән башка, сатып алучыларны шулай ук авыл жирлекләреннән алып килеп корган палаткалар да жәлеп итте.
Ярминкәдә урманнарда һәм посадкалардан жыелган гомбәләрне дә сатып алырга була иде. Яшелчәләргә килгәндә, кәбестә - 8 сум/кг, бәрәнге - 12 сум/кг, чогендер - 13 сум/кг, суган һәм кишер - 15әр сум/кг... Ләмберә, Старошайгово, Рузаевка районнарыннан килгән эшмәкәрләр жи-меш агачлары, куаклар, чәчәк vсентеләре белән дә сату иттеләр. Арзангарак сатып аласы, кыйммәтрәк сатасы - ярминкәдә бу аксиома әһә-миятле тvгел иде. Кvрәмсен, яр-минкә - ул базар тvгел, сатулашу урынсыз, дип уйлаганнардыр сатучылар һәм шуна да алар бәяләрне алдан ук килешеп куйганнар, алай гына да тvгел, vзләренен сатып алучыларын, кадерле кунаклар кебек, сыйладылар да.
- Ромодан районы сатучыларыннан мин шикәр комы сатып алдым. Ә яшелчәләрнен югары сыйфатлыларын «Тепличный»дан (берничә машинада) сатарга алып чыкканнар; кишерләре белән суганнарын алдым. Кешеләр килеп чиратта тормый гына кирәк ашамлыкларын алып китә бардылар, шул ягы сатып алучылар очен бик тә унай булды, - дип сойләде Рахилә Әминулла кызы Исмаилова. - Кvнелгә хуш килгәннәренен тагы бер ягы – волонтерлар олыларга алган әйберләрен «Газель»ләргә кадәр кvтәреп алып барырга ярдәм иттеләр, ә «Газель»ләр тvләvсез шәһәрнен һәрбер районына кадәр илтеп тә куя бардылар, - диде ул.
- Әйе, ярмарка бик кvнелле, яхшы узды, ул шулай булырга тиеш тә, - дип сvзгә кушылды пенсия яшендәге кvрше хатыны Александра Егор кызы Евсеева. - Бернәрсә дә сатып алмасан да, чыгып жырлар, такмаклар тынлыйсын, танышлар белән очрашып

сойләшәсен. Ярмаркачылар очен чәй-кофе, шашлык белән сыйланып алырга да момкинчелекләр тудырылган иде. Шулай Саранскта тагы бер ярморка vтте.

**Н.Хәлил**